МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.02.2019 г.Казань № 38/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында” 2017 елның 29 мартындагы 60/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Авыл хуҗалыгын үстерүнең һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы турында” 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2018 елның 17 гыйнварындагы карары нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында” 2017 елның 29 мартындагы 60/2-пр номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 26.04.2017 № 92/2-проекты, 27.09.2017 № 219/2-пр, 21.02.2018 № 39/2-пр, 10.07.2018 № 158/2-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

2. Эш башкару һәм контроль бүлегенә (Р.К.Баһаутдиновка) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына җиткерергә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары - министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 28.02.2019
38/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында” 2017 елның 29 мартындагы 60/2-пр номерлы боерыгына кертелә торган**
**үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында” 2017 елның 29 мартындагы 60/2-пр номерлы боерыгының (алга таба - Боерык) кереш өлешендә «2013 - 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Боерык белән расланган “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында (алга таба - Программа):

Программаның паспортында:

«Программаны эшләү турында карар кабул итү датасы (аны раслау датасы, тиешле норматив актның исеме һәм номеры)» графасында «2013 - 2020 елларга» сүзләрен «2013-2021 елларга» сүзләренә алыштырырга;

«Программа чарараларының тасвирламалары» графасында 2, 3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Терлекчелек фермаларын сатып алу, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау яисә модернизацияләү;

3. Терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча җитештерү объектларын сатып алу, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау яисә модернизацияләү;»;

«Программаны гамәлгә ашыру сроклары» графасында «2019 ел - 30 гаилә фермасы булдыру, 90 эш урыны; 2020 ел - 30 гаилә фермасы булдыру, 90 эш урыны» сүзләрен «2019 ел - 15 гаилә фермасы булдыру, 45 эш урыны; 2020 ел - 15 гаилә фермасы булдыру, 45 эш урыны» сүзләренә алыштырырга;

«Программаның төп төшенчәләре» бүлегендә бишенче һәм алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«терлекчелек фермаларын сатып алу, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау яисә модернизацияләү;

терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча җитештерү объектларын сатып алу, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау яисә модернизацияләү;»;

«Гаилә фермаларын гамәлгә кертү» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаилә фермаларын гамәлгә кертү

| Эшчәнлек юнәлеше | КФХлар саны, берәмлек | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | Дүрт елда, барысы |
| сөтчелек | 12 | 12 | 6 | 6 | 36 |
| эре мөгезле терлекләр симертү | 11 | 11 | 5 | 5 | 32 |
| сарык фермалары | 3 | 3 | 1 | 1 | 8 |
| кошчылк | 3 | 3 | 2 | 2 | 10 |
| ат фермалары | 1 | 1 | 1 | 1 | 4 |
| Барысы | 30 | 30 | 15 | 15 | 90»; |

5 бүлектә:

1 пунктта «2013 - 2020 елларга» сүзләрен «2013-2021 елларга» сүзләренә алыштырырга;

2, 4 һәм 5 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

7 пунктның икенче абзацында «2013 - 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

Программага 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, АНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ЧАРАЛАРЫН ФИНАНСЛАУ

| Максатлар | Бурычлар | Төп чаралар | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү сроклары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар үлчәме | | | | Финанслау чыганаклары күрсәтелеп, финанслау (млн. сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| Авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү | 90 гаилә терлекчелек фермасын булдыру | Гаилә терлекчелек фермаларын сатып алу, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау яисә модернизацияләү, шулай ук техника, җайланмалар һәм терлекләр белән комплектацияләү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2017 - 2020 еллар | Гаилә терлекчелек фермалары санын арттыру, берәмлек | 30 | 30 | 15 | 15 | Барысы - 259; шул исәптән 55 – Татарстан Республикасы бюджеты; 100 - федераль бюджет; 104 – җәлеп ителгән акчалар | Барысы - 259; шул исәптән 55 – Татарстан Республикасы бюджеты; 100 - федераль бюджет; 104 – җәлеп ителгән акчалар | Барысы - 584; шул исәптән 147 – Татарстан Республикасы бюджеты; 203 – федераль бюджет; 234 – җәлеп ителгән акчалар | Всего - 584; шул исәптән 147 – Татарстан Республикасы бюджеты; 203 – федераль бюджет; 234 – җәлеп ителгән акчалар». |
| | | | | | Булдырыла торган өстәмә эш урыннары саны | 90 | 90 | 45 | 45 | | | | |

3. Боерык белән расланган Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта «2013 - 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Грант күләме, КФХның үз акчаларын һәм аның чыгымнар планын исәпкә алып, Министрлык тарафыннан билгеләнә. Итчелек һәм сөтчелек юнәлешләрендә эре мөгезле терлекләр үрчетү өчен грантның максималь күләме бер хуҗалыкка иң күбе 30,0 млн. сум тәшкил итә һәм ул чыгымнарның 60 процентыннан артык була алмый, чыгымнар планында күрсәтелгән өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча; башка авыл хуҗалыгы хайваннары төрләрен, кош-кортлар һәм балыклар үрчетү һәм тоту өчен - бер хуҗалыкка иң күбе 20 млн.сум, әмма ул чыгымнарның 60 процентыннан артык була алмый, чыгымнар планында күрсәтелгән өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча.»;

пункта 2.5 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) КФХ башлыгы һәм әгъзалары элегрәк яңа эш башлаучы фермерлар өчен грантлар һәм гаилә терлекчелек фермаларын үстерү өчен грант алучылар булмаган булсалар йә гаилә фермалары һәм яңа эш башлаучы фермерлар өчен алынган грант тулысынча тотылган датадан ике елдан артыграк узган булса, беренче проект буенча булдырылган авыл хуҗалыгы хайваннарының баш саны һәм даими эш урыннары икенче проект буенча йөкләмәләр узу срогына кадәр сакланып калганда. Шул ук вакытта бер үк чыгымнарны грант исәбеннән финанслау рөхсәт ителми;»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Чыгымнар планы нигезендә грант Грант алучы тарафыннан түбәндәгеләргә тотыла:

гаилә терлекчелек фермаларын төзүнең, реконструкцияләүнең яисә модернизацияләүнең проект документациясен эшләүгә;

гаилә терлекчелек фермаларын сатып алуга, төзүгә, реконструкцияләүгә яисә модернизацияләүгә;

терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча җитештерү объектларын сатып алуга, төзүгә, реконструкцияләүгә яисә модернизацияләүгә;

терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясен эшкәртү объектларын җайланмалар һәм техника белән (үсемлекчелек продукциясен җитештерү өчен билгеләнгән авыл хуҗалыгы техникасыннан тыш) комплектацияләүгә, шулай ук аларны монтажлауга;

авыл хуҗалыгы хайваннары сатып алуга.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Гаилә терлекчелек фермасын үстерүгә кабат грант алу элек алынган грант тулысынча тотылганнан соң 24 ай узгач һәм беренче проект буенча булдырылган авыл хуҗалыгы хайваннарының баш саны һәм даими эш урыннары икенче проект буенча йөкләмәләр узу срогына кадәр сакланып калганда гына мөмкин.»;

3.1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.6. Соңгы 24 ай өчен һәм соңгы хисап датасына «Авыл хуҗалыгы культуралары уңышын җыю турында» №2-фермер һәм (яисә) «Терлекчелек продукциясен җитештерү һәм терлекләрнең баш саны турында белешмәләр» № 3-фермер формалары буенча дәүләт статистика күзәтчелеге органнарына хисаплар;»;

3.1.18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.18. КФХ башлыгының хезмәт кенәгәсе күчермәсен, эш (хезмәт) эшчәнлеге беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш;»;

3.1.21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.21. Соңгы хисап датасына, хисапны кабул итү турында фонд билгесе белән, Пенсия иминияте фондына хисап күчермәсен (РСВ-1 ПФР яисә СЗВ-М формасы);».